| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САЛИХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛИХ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.05 2023 г. с.Новые Чути № 8

Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген раслау.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Салих авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Сәлих авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАРЫ:

1. Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Салих авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгын хайваннарның элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз хайваннарны кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам .

Җитәкчесе З. С. Галләметдинов